Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил
№ 19
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
№ под-9233/15
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы
№ 533
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы
№ 01-02/629
«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы
№ 3022-П

**БОЕРЫК**

2015 елның 02 сентябре

**"Ребенок в мире прав" – "Бала хокук даирәсендә" мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсы турында**

Бала хокуклары турында БМО Конвенциясен популярлаштыру, балаларны һәм яшьләрне мәгълүмати-хокукый агарту, аларны социаль-хокукый активлыкка этәрү, шулай ук үсеп килүче яшь буынның хокукый белемне һәм хокукый культураны арттыру өлкәсендәге позитив юнәлешле, иҗтимагый-файдалы иҗади эшчәнлеген пропагандалау максатларында боерабыз:

1. "Ребенок в мире прав" – «Бала хокук даирәсендә" мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсын (алга таба – Конкурс) гамәлгә куярга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

2.1. "Ребенок в мире прав" – «Бала хокук даирәсендә" мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсы турында нигезләмә;

2.2. Конкурсның оештыру комитеты составы;

2.3. Конкурсның жюри составы.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратына йөкләргә.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил | Г.Л.Удачина |
| Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры | Э.Н.Фәттахов |
| Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министры | В.А.Леонов |
| Татарстан Республикасы Юстиция министры | Л.Ю.Глухова |
| «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе | А.Р.Зарипов |

Түбәндәге боерыклар белән расланды:
Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил № 19
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы № под-9233/15
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы № 533
Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгы № 01-02/629
«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы № 30-П
2015 елның 2 сентябре

**“Ребенок в мире прав” – «Бала хокук даирәсендә” мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсы турында нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. “Ребенок в мире прав” – «Бала хокук даирәсендә” мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсы (алга таба – Конкурс) Бала хокуклары турында БМО Конвенциясен популярлаштыруга, балаларны һәм яшьләрне мәгълүмати-хокукый агартуга, аларның социаль-хокукый активлыкка этәрүгә, шулай ук үсеп килүче яшь буынның хокукый белемне һәм хокукый культураны арттыру өлкәсендәге позитив юнәлешле, иҗтимагый-файдалы иҗади эшчәнлеген пропагандалауга юнәлтелгән.

1.2. Конкурс ел саен - быел 10 сентябрьдән 20 ноябрьгә кадәр үткәрелә. Конкурсны үткәрү турында мәгълүмат гамәлгә куючыларның һәм оештыручыларның рәсми сайтларында быелның 9 сентябреннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

1.3. Конкурсны үткәрү чараларын финанслау бюджет буенча законнарда каралган тәртиптә һәм хәйрия буларак кергән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**2. Конкурсның төп максатлары һәм бурычлары**

2.1. Конкурсның төп максатлары:
балаларның һәм яшьләрнең актив гражданлык позициясен булдыру;

балалар һәм яшьләр мохитендә хокукый белем һәм традицион кыйммәтләрне пропагандалау;

халыкның хокукый белемен һәм хокукый культурасын арттыру өлкәсендә балаларның һәм яшьләрнең позитив юнәлешле, иҗтимагый файдалы иҗади эшчәнлеген пропагандалау;

медиапродуктлар иҗат итү буенча яшьләрнең иҗади күнекмәләрен камилләштерү.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:

җәмәгатьчелекнең игътибарын хокукый культураны арттыруның актуаль мәсьәләләренә җәлеп итү;

җәмәгатьчелекнең хокукый кагыйдәләрне һәм нормаларны тотрыклы позитив кабул итүен формалаштыру;

хокукый күрсәтмәләрне ихтыярый үтәү һәм башкару принцибына тотрыклы позитив мөнәсәбәт формалаштыру зарурлыгына җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итү;

талантлы яшьләрне ачыклау һәм кызыксындыру;

медиамәгариф һәм медиаиҗатның эчтәлеген, рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү.

## 3. Конкурсны гамәлгә куючылар һәм оештыручылар

3.1. Конкурсны гамәлгә куючылар: Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Конкурсны гамәлгә куючылар).

3.2. Конкурсны оештыручылар: Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф идарәләре һәм яшьләр эшләре һәм спорт идарәләре органнары (килешү буенча), «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы” Региональ иҗтимагый оешмасы (килешү буенча).

3.3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен гамәлгә куючыларның һәм оештыручыларның вәкилләреннән оештыру комитеты төзелә (алга таба – Оештыру комитеты).

3.4. Иң яхшы эшләрне бәяләү һәм ачыклау өчен рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм әгъзалар составында 13 кешедән торган жюри төзелә.

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1. Конкурста 6 яшьтән 30 яшькә кадәрге физик затлар, аерым гына да, төркем булып яки иҗат коллективлары аша катнаша ала.

## 5. Конкурсны оештыру һәм үткәрү шартлары

5.1. Конкурска Бала хокуклары турында БМО Конвенциясе нигезендә баланың бер яисә берничә хокукы эчтәлеген чагылдыра торган видеороликлар тәкъдим ителә.

Видеороликның жанрын катнашучылар мөстәкыйль билгели (интервью, репортаж, видеоклип, мультфильм һ.б.)

5.2. Конкурска тәкъдим ителгән видеороликлар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

халыкның хокукый белеме һәм хокукый культурасын формалаштыруга һәм югары дәрәҗәдә тотуга юнәлгән булуы;

сюжетның кыска һәм мәгълүматка бай булуы;

видеороликның 2 минуттан артык дәвам итмәве;

видеороликның эчтәлеге Россия Федерациясе законнарына каршы килмәскә тиеш. Конкурска реклама характерындагы, сүгенү һәм хурлау сүзләре кертелгән, шулай ук, Конкурс тематикасына туры килми торган видеороликлар кабул ителми.

5.3. Конкурста катнашу өчен дәгъва итүче бу елның 10 сентябреннән 31 октябренә кадәр теләсә кайсы электрон чыганакта (CD яисә DVD диск, флеш-туплама һ.б.*)* видеоролик һәм әлеге Нигезләмә кушымтасына таянып язылган гаризаны Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына 420015, Казан ш., Карл мМаркс ур., 61нче йорт (2 кат) адресы белән яки rebenok-v-mire-prav@yandex.ru электрон адресына юллый.

Әлеге пунктта күрсәтелгән вакыттан соң тапшырылган гаризалар һәм эшләр кабул ителми.

5.4. Дәгъва итүче Конкурста катнаша торган видеороликны теләсә кайсы социаль челтәрдә урнаштыра ала, бу вакытта ул заявкасында видеога сылтама бирергә тиеш.

5.5. Конкурс өч этапта үткәрелә.

I этап – заявки биру (быелның 10 сентябреннән 31 октябренә кадәр).

Беренче этапта Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты беркетелгән видеороликлар белән бергә Конкурска катнашуга гариза кабул итә. Гаризасы һәм видеороликы кабул ителеп алынганнан соң, дәгъва итүчегә өч көн эчендә заявкада күрсәтелгән электрон адресы яки телефон аша материалларының кабул ителүе турында хәбәр ителә.

II этап - сайлап алу (быелның 1 ноябреннән 10 ноябренә кадәр).

Бу этапта жюри Конкурска кергән эшләрне карый һәм, әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Конкурска тәкъдим ителгән видеороликларны сайлый. Сайлап алу этабы нәтиҗәләре турында мәгълүмат 11 ноябрьдән дә соңга калмыйча Конкурсны гамәлгә куючыларның рәсми сайтларында урнаштырыла.

III этап – йомгаклау (быелның 11 ноябреннән 17 ноябренә кадәр).

Өченче этапта жюри әлеге Нигезләмәнең 5.6 пунктында билгеләнгән критерийлар нигезендә эшләрне бәяли.

5.6. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары:

Конкурсның төп максатларына һәм бурычларына туры килү;

креативлык (яңа идея, оригинаильлек);

максатчан төркемнәргә тәэсире буенча нәтиҗәлелеге;

сюжетның кыска һәм мәгълүматка бай булуы;

әйтәсе килгән фикерне чагылдыра белү осталыгы;

эшнең тормышчанлыгы һәм танып белүгә юнәлгәнлеге, мантыйкка сыешуы һәм эзлеклелеге;

теманың тулысынча ачылуы;

ролик эчтәлегенең аңлатмасына туры килүе, видеороликның сыйфаты.

Баллар һәр критерий буенча ун баллы шкала аша билгеләнә.

5.7. Жюриның һәр әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 5.6 пунктында билгеләнгән критерийлар буенча һәрбер эшне бәяләп чыга.

5.8.б Балларның суммасы буенча Конкурста катнашучыларның рейтингы төзелә.

5.9. Рейтинг нигезендә Конкурста катнашучыларның исемлеге формалаша.

Иң күп балл җыйган 10 автор Конкурс җиңүчесе дип танылa. Баллар саны бертигез булган очракта, утырышта катнашучылар җиңүчене ачык тавыш биру юлы белән ачыклыйлар. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

5.10. Җиңүчеләр исемлеге беркетмә белән рәсмиләштерелә. Аңа жюри рәисе имза сала. Җиңүчеләр исемлеге Конкурска йомгак ясалган тантаналы кичәдә быелның 20 ноябрендә игълан ителә.

Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасыннан соң әлеге протокол Конкурсны гамәлгә куючыларның рәсми сайтларында урын ала.

5.11. Жюри эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Жюри утырышы әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 2/3се катнашкан очракта хокуклы дип санала.

Жюри утырышын аның рәисе, ә ул югында – жюри рәисе урынбасары алып бара.

5.12. Социаль челтәрдә урнаштырылган вилеороликка карата уңай фикерләр саныннан чыгып, «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы" Региональ иҗтимагый оешмасы әлеге Нигезләмәнең 4.5 пункты буенча быелның 17 ноябреннән дә саңга калмыйча тамашачы мәхәббәте призына ия булучыны билгели.

## 6. Конкурска йомгак ясау

6.1. Конкурсның III этабына узган барлык катнашучылар Конкурста катнашу турында таныклык алалар.

6.2. Конкурста җиңүчеләрнең һәркайсы диплом һәм 20 000 (егерме мең) сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләнә.

6.3. Тамашачы мәхәббәте призына ия булучы 10 000 сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләнә.

6.4. Җиңүчеләр быелның 20 ноябрендә – Бөтендөнья балалар көнендә тантаналы шартларда бүләкләнә.

Бүләкләү тантанасына катнашырга чакырылучыларны Конкурсны Оештыру комитеты билгели.

Тантананың кайда һәм кайсы вакытта үткәрелүе турында мәгълүмат быелның 18 ноябреннән дә саңга калмыйча, Конкурсны гамәлгә куючыларның рәсми сайтларына урнаштырыла.

## 6. Өстәмә мәгълүмат

7.1. Конкурска видеоролик җибәреп, автор Конкурсны оештыручыларга тәкъдим ителгән материалдан, авторның исемен һичшиксез күрсәтеп, файдалану хокукы (Интернет челтәрендә, телепрограммаларда урнаштыру, иҗади проектларда катнашу, алга таба рецензияләү һәм тиражын арттыру һ.б.) бирә.

7.2. Конкурста катнашучылар яисә аларның законлы вәкилләре үзләренең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалык бирәләр.

7.3. Конкурска тәкъдим ителгән видеороликлар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

“Ребенок в мире прав – “Бала хокук даирәсендә”
мәгълүмати-социаль видеороликлар
республика конкурсы турында нигезләмәгә
Кушымта

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсында катнашуга**
**ГАРИЗА**

1 Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме

2 Туу датасы, тулы яше

3. Эшнең исеме

4 Видеороликның жанры

5 Почта адресы

6 Электрон адресы

7 Элемтә өчен телефон (шул исәптән мобиль телефон)

8 Мәгариф оешмасы исеме, сыйныф (булган очракта)
9. Видеороликның социаль челтәрләрдә урнаштырылганлыгы турында мәгълүмат (сылтаманы күрсәтергә)

Имза _______________________/ /
2014 елның «_______» ________________

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык бирәм ___________ / __________

* Балигъ булмаганнар исеменнән аларның законлы вәкилләре ризалык бирә.

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсында катнашуга ГАРИЗА**

1 Иҗат коллективының исеме (булган очракта)

2 Иҗат коллективының составы (Ф.И.А.ис., туган датасы, катнашучыларның эшләү яиса уку урыны)

3. Эшнең исеме

4 Видеороликның жанры

5 Почта адресы

6 Электрон адресы

7 Элемтә өчен телефон (шул исәптән мобиль)

8. Видеороликның социаль челтәрләрдә урнаштырылганлыгы турында мәгълүмат (сылтаманы күрсәтергә)

Коллектив җитәкчесенең имзасы ____________ / /

2014 елның «_______» _____________

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык бирәбез ** ____________ / ___________
____________ / ___________
____________ / ___________

*Булган очракта тутырыла
** Иҗади оешманың бөтен катнашучылар ризалык бирә. Балигъ булмаганнар исеменнән аларның законлы вәкилләре ризалык бирә.

Түбәндәге боерыклар белән расланды:
Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил № 19
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы № под-9233/15
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы № 533
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы № 01-02/629
«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы № 30-П
2015 елның 2 сентябре

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсының оештыру комитеты**

| | |
|---|---|
| Удачина Гүзәл Лүбис кызы | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Оештыру комитеты рәисе |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы | «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы башлыгы урынбасары |
| Гарифуллин Рөстәм Марат улы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары |
| Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызы | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре (килешү буенча) |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы Юстиция министры |

| | |
|---|---|
| Согрина Екатерина Игоревна | «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы” ИО директоры |
| Сулима Лариса Олеговна | Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары |

Түбәндәге боерыклар белән расланды:
Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил № 19
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы № под-9233/15
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы № 533
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы № 01-02/629
«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы № 30-П
2015 елның 2 сентябре

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсының оештыру комитетының жюри составы**

| | |
|---|---|
| Удачина Гүзәл Лүбис кызы | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил - жюри рәисе; |
| Сулима Лариса Олеговна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары – жюри рәисе урынбасары; |
| Гавва Светлана Владимировна | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының өстәмә белем һәм социаль программалар бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе - жюри секретаре; |

Жюри әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы | «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы башлыгы урынбасары |
| Әхмәтшин Айрат Сәет улы | Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Тикшерү |

| | |
|---|---|
| | комтетының тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасары |
| Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызы | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре (килешү буенча) |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы Юстиция министры |
| Демидов Виктор Николаевич | Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Юстиция министрлыгы идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Долгов Марат Шамил улы | Татарстан Республикасы прокуроры урынбасары (килешү буенча) |
| Забегина Татьяна Вениаминовна | Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сабурская Сәрия Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча); |
| Сәхәбетдинова Рамилә Әхмәтзакир кызы | «Яңа гасыр» ТРК «Балалар һәм яшьләр тапшырулары» иҗат берләшмәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Согрина Екатерина Игоревна | «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы” ИО директоры (килешү буенча) |

_______________________